ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2022 г. Заинск №350

**«2022 елның 3 кварталына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирелә торган барлык категория гражданнар өчен, шул исәптән «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасында катнашу өчен социаль түләүләр күләмен исәпләүгә 2022 елның өченче кварталына Зәй муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда) 69261 (алтмыш тугыз мең ике йөз алтмыш бер) сум күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.
3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
юрист